МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.11.2024 Казан шәһәре № 252-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2022 елның 21 мартындагы 48-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреж-дениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пункты-ның икенче абзацы нигезендә Энер-гетика һәм энергетика ресурслары нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумын уздыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Энергетика һәм энергетика ресурслары нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумын уздыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 мартындагы 48-ОД номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2023 елның 22 мартындагы 49-ОД номерлы, 2024 елның 16 июлендәге 147-ОД номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аңа карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының

1 пунктының икенче абзацы нигезендә Энергетика һәм энергетика ресурслары нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумын уздыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$З_{13}$ – Форум программасы нигезендә чакырылган спикерларның һәм форумда катнашучы югары дәрәҗәдәге делегатларның катнашуына бәйле чыгымнар (очыш яисә тимер юл аша чыгу өчен түләү, аэропорттагы аерым юл өчен түләү, аэропорттагы бизнес-зал өчен түләү, кунакханәдә яшәү өчен түләү, транспорт белән тәэмин итү, туклану белән тәэмин итү, тәрҗемәче ярдәме, бүләкләр алу һ.б.);».

2. Хокук бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чорда дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Җыелма бүлеккә бу боерыкны теркәгән көннән алып бер эш көне эчендә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында әлеге боерыкны урнаштырырга, шулай ук әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко